| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ** |

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
| **12.05.2017** | г.Казань | **№ 01-02/41** |

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен
коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр
факты турында эш бирүче вәкиленә белдерү тәртибен раслау турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр факты турында эш бирүче вәкиленә белдерүнең әлеге тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгына (Латыева Т.Ю.):

дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

Тәртипне Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Коррупциягә каршы сәясәт» мәгълүмат стендына урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларындагы мәгълүматларны мәгълүмат стендларына урнаштыру өчен җаваплы затларга Тәртипне суд участоклары стендларына урнаштырырга.

4. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (А.Г.Сафин) әлеге боерыкны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы сайтының “Коррупциягә каршы тору” бүлегенә урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Дәүләт граждан хезмәткәрен коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр

фактлары турында эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленә белдерү тәртибе турында» 2009 елның 16 октябрендәге К-128/03-03 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз карамагымда калдырам.

Министр Л.Ю.Глухова

Татарстан Республикасы юстиция
министрының
12.05.2017 № 01-02/41
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр факты турында эш бирүче вәкиленә белдерү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр факты турында эш бирүче вәкиленә белдерү тәртибе (алга таба - Тәртип) “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ Федераль законның 9 статьясының 5 өлеше нигезендә эшләнгән.

Тәртип Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - граждан хезмәткәрләре, Министрлык) эш бирүче вәкиле булып торучы Татарстан Республикасы юстиция министрына (алга таба - министр) аларны коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр факты турында белдерү процедурасын регламентлый.

2. Коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгать фактлары турында эш бирүче вәкиленә белдерү, мондый фактлар буенча тикшерү эшләре үткәрелгән яки әле үткәрелә торган очраклардан тыш, граждан хезмәткәренең вазыйфаи (эш) бурычы булып тора.

3. Коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгать факты турында эш бирүче вәкиленә белдерү (алга таба - Белдерү) граждан хезмәткәре тарафыннан Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә язма формада төзелә.

Белдерүдә түбәндәге мәгълүматлар чаылдырылырга тиеш:

белдерү җибәрүче затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, биләгән вазыйфасы һәм структур бүлекчә, яшәү урыны һәм телефон номеры;

Министрлыкның граждан хезмәткәренә аларның вазыйфаи бурычларын үтәүләренә бәйле рәвештә кайсыдыр затларның аларны коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгать факты булган (мондый очраклар билгеле булган) хәлнең тасвирламасы (көне, урыны, вакыты, башка шартлар);

граждан хезмәткәре тарафыннан алынган, коррупцион хокук бозу гамәленә

этәрүне раслый торган мөрәҗәгатьнең (башка затның хезмәткәргә мөнәсәбәттә башкарылган гамәле, тәкъдиме, гаризасы, таләбе, башка формадагы мөрәҗәгате) тулы тасвирламасы, шулай ук граждан хезмәткәрен аларны гамәлгә ашыруга этәргән, кооррупцион хокук бозу билгеләрен эченә алган гамәлнең тасвирламасы;

коррупцион хокук бозуга этәрүче физик (юридик) зат турында билгеле булган барлык мәгълүматлар;

хокук бозуга этәрүнең ысулы һәм шартлары (сатып алу, янау, алдау һ.б), шулай ук затның коррупцион хокук бозуны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимен кабул итүдән аш тарту (ризалык ирү) турындагы мәгълүмат;

белдерүне прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына (ниндиләр) юллау көне.

Белдерүгә кайсыдыр затларның граждан хезмәткәрен коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгать итүләре очрагын раслый торган булган барлык материаллар да теркәлә.

4. Белдерү министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) исеменә языла һәм кичектергесез рәвештә коррупцион һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба - Җаваплы зат) тапшырыла, мондый тәкъдим эш вакытыннан тыш вакытта кергән очракта, эш урынына килеп җитү белән кичектергесез рәвештә.

Мондый хәл граждан хезмәткәре вазыйфа (эш) урынында булмаган, яки даими эш урыныннан читтә булган чакта килеп чыккан очракта Белдерү почта аша, факсимиль элемтә каналы аша яки электрон элемтәнең башка уңайлы юлы белән җибәрелергә мөмкин һәм Белдерүнең төп нөсхәсе эш урынына кайту белән Җаваплы затка тапшырыла.

5. Җапавлы зат Белдерүне, Тәртипкә 2 нче кшымта нигезендә, Дәүләт хезмәткәрен коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр факты турында эш бирүче вәкиленә бирелгән белдерүләрне теркәү журналына (алга таба - Журнал) терки.

6. Белдерү Журналга теркәлгәннән соң граждан хезмәткәренә Белдерүнең Белдерүне кабул итүче зат турында мәгълүматлар һәм аны теркәү көне күрсәтелгән күчермәсе имза куйдырып бирелә. Белдерү почта аша кергән очракта Белдерүнең күчермәсе граждан хезмәткәренә заказлы хат белән почта аша җибәрелә.

Бедерүне теркәүдән баш тартуга, шулай ук Белдерүнең күчермәсен бирмәүгә юл куелмый.

Алынган мәгълүматларның конфеденциальлеге “Персональ мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законы таләпләре нигезендә тәэмин ителә.

7. Җавапл зат Белдерүне теркәгән көнне үк аны  эчке эшләр органнарына яки башка дәүләт органнарына юллау турында карар кабул итү өчен карарга министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

8. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан Белдерүне эчке эшләр органнарына яки башка дәүләт органнарына юллау турында карар кабул ителгән очракта Җаваплы зат материаллар теркәлгән Белдерүне  юллауны мондый карар кабул ителгән көннән ике эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашыра.

9. Коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр факты турында эш бирүче вәкиленә, прокуратура яки башка дәүләт органнарына белдергән граждан хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавы астында тора.

10. “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Министрлыкның граждан хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү факты турында эш бирүче вәкиленә белдерү турындагы бурычларын үтәмәүләре үз артыннан аларны дәүләт хезмәтеннән азат итүне яки Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр җаваплылыкка тартуны ияртүче хокук бозу булып тора.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен
коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан
мөрәҗәгатьләр факты турында эш
бирүче вәкиленә белдерү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
юстиция министрына
____________________________________
____________________________________
(Ф.И.Ә.и., вазыйфасы һәм структур бүлекчәсе,
____________________________________
яшәү урыны адресы,
____________________________________
телефон номеры)

Хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгать факты турында
эш бирүче вәкиленә белдерү

Мине коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан
________________________________________________________
(Ф.И.Ә.и., вазыйфасы, хокук бозуга этәрүче физик (юридик) зат турында
______________________________________________________________________
билгеле булган барлык мәгълүматлар
ягыннан мөрәҗәгать булуы турында белдерәм.

Хокук бозуга этәрү минем тарафтан
____________________________________________________________________
(граждан хезмәткәре тарафыннан алынган, коррупцион хокук бозу гамәленә этәрүне раслый торган мөрәҗәгатьнең
______________________________________________________________________
(башка затның хезмәткәргә мөнәсәбәттә башкарылган гамәле, тәкъдиме, гаризасы,
______________________________________________________
таләбе, башка формадагы мөрәҗәгате) тулы тасвирламасы күрсәтелә, шулай ук граждан хезмәткәрен
______________________________________________________________________
аларны гамәлгә ашыруга этәргән, коррупцион хокук бозу билгеләрен эченә алган гамәлнең тасвирламасы
гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

Хокук бозуга этәрү түбәндәге юл белән гамәлгә ашырылды _______________
______________________________________________________________________
(хокук бозуга этәрүнең ысулы һәм шартлары: сатып алу, янау, алдау һ.б., шулай ук затның коррупцион хокук бозуны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимен кабул итүдән баш тарту (ризалык бирү) турындагы мәгълүмат)

Хокук бозуга этәрү ______________________________
______________________________________________________________________
(телефон аша сөйләшкәндә, күзгә-күз сөйләшкәндә, смс-хәбәрдә, социаль челтәрдә аралашканда һ.б.)
булды.

Хокук бозуга этәрү ________ сәг. ________ мин., ___________20__ елның «___»
________________________________________________________ булды.
(шәһәр, адрес)

Шулай ук ____________________________________
(прокуратура яки башка дәүләт органнарына (ниндиләр)
______________________________________________________________________
белдерү җибәрелү датасы

белдерү җибәрелүен дә хәбәр итәм.

| ______________ | ______________ | ______________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (имзаның тулы язылышы) |

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен
коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан
мөрәҗәгатьләр факты турында эш
бирүче вәкиленә белдерү тәртибенә
2 нче кушымта

Дәүләт хезмәткәрен коррупцион хокук бозу гамәленә этәрү максатыннан мөрәҗәгатьләр факты турында эш бирүче вәкиленә бирелгән белдерүләрне теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Белдерү бирүченең Ф.И.Ә.и., вазыйфасы | Белдерү бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.Ә.и. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |